БОМБАДАН КАЧЫП

Донбасс якларыннан күченеп килүчеләр Татарстанда яңа тормыш башламакчы

> 2

БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘРБИЯ

Ярыша-ярыша мал җыйганда әхлак белән исәпләшү мөмкин микән?

> 2



ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

«ВТ» укучыларының күңелендә сакланган хатирә-истәлекләре

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 50 (28823) | Шимбә | 9 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АКЧАСЫ БАР, БАКЧАСЫ КИРӘК

Фермерлар мәктәбе

Казанда туып-үсеп, бүген Лаеш районында яшәүче Оксана Посадская бизнес өчен гадәти булмаган юнәлеш сайлаган. Быелдан башлап ул... фундук чикләвеге үстерү белән шөгыльләнмәкче.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Барысы да мин теләгәнчә булыр дип өметләнәм, – ди ул. – Моңа кадәр Татарстанда фундук чикләвеге үстерүче булмаган. Ә мин, тәвәккәлләп, тотынып карарга булдым. Бу һич уйламаган җирдән барлыкка килгән идея түгел. Гаиләбез белән бергәләп әлеге үсемлек турында барысын да өйрәндек. Үз вакытында академик Александр Яблоков моның белән бик җитди шөгыльләнгән һәм хәтта аларның сортларын чыгарган. Фундук бит ул – икенче төрле чикләвек куагы. Каенга бик охшаш. Ә ул, белгәнегезчә, бөтен Россиядә үсә.

Булачак эшмәкәр әйтүенчә, фундук Самара өлкәсендә дә мул уңыш бирә. Әлегә Оксана кайсы районда утыртачагын хәл итмәгән. Төгәл урыны июньдә билгеле булыр, ди.

– Берничә вариант бар, чөнки күп районнарга чакыралар. Әлегә җир кишәрлекләрен карыйбыз, андагы туфракны өйрәнәбез. Гомумән алганда, фундук туфракка нәзберек түгел. Үндырышлы, җиңел, йомшак туфрак ярата. Иң мөһиме – кызыл балчык булмасын. Урынны шул таләпләргә туры китереп сайлаячакбыз. Бу эшләрне кар эреп беткәч кенә башкарырга мөмкин булачак, – ди Оксана Посадская.

Беренче генә тәҗрибәсе булса да, фермер яхшыга өметләнә. Шушы көннәрдә башка төбәкләргә укырга барырга да планлаштыра.

– Куакларны көзен утыртырга уйлыйбыз. Беренче партиясен Кырымдагы питомниктан сатып алдык. Башка төбәкләрдән дә төрле сортлар алып кайтырга ниятлибез. Аларның төрле төрдәгесен утыртасыбыз килә, ләкин төп игътибарны Кырым сортына бирәчәкбез, – диде ул.

Оксана – Татарстанда узган «Фермерлар мәктәбе» проектының җиңүчесе. Анда үзләрен киләчәктә терлекчелек, игенчелек, атчылык һәм үсемлекчелек буенча сынап карарга теләгән 40 кеше белем алган. Биредә эшмәкәрлекнең барлык нечкәлекләренә өйрәтәләр, чит ил аграрийларының тәҗрибәләре белән уртаклашалар. Моннан тыш, агробизнес өчен уңышлы булган маркетплейсларда эшләргә өйрәтәләр.

Россельхозбанк, Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Казан дәүләт аграр университеты белән берлектә тормышка ашырыла торган проектта катнашып җиңү яулаучылар 345 мең сум күләмендә грант белән бүләкләнгән.

Россельхозбанкның Татарстан төбәк филиалы директоры Ләлә Кодәрмәтова искәрткәнчә, «Фермерлар мәктәбе» – авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләүдә уникаль проект.

– Бүген авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү аеруча мөһим. Республиканы азык-төлек белән тәэмин итүгә үз эшен ярата торган фермерлар зур өлеш кертә. Сезнең идеяләр һәм бизнес-проектларның чит илдән кайтарыла торган ризыкларны алыштыру максатында үз өлешен кертүенә шикләнмим, – диде ул проект җиңүчеләренә.

Проектның уңышлы булуына фермерлар да кат-кат басым ясады.

– Бизнес алып бару буенча төп белемне «Фермерлар мәктәбе» бирде, – ди Оксана Посадская. – Анда бик күп яңалык алдым. Алга таба эшләү куркыныч түгел, чөнки башка фермерларның да тәҗрибәсен күрдек. Безгә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында да күп сөйләделәр. Үзем дә киләчәктә министрлык программасында катнашып, грант алырга планлаштырам.

Проектта барлыгы өч җиңүчене сайлап алганнар. Рөстәм Гобәйдуллин 100 башка исәпләнгән ферма ачарга тели. Шамил Амагомедов исә атчылык буенча бизнес-проектын уңышлы яклаган.

Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында яшәүче Рөстәм Гобәйдуллинның фермерлык белән шөгыльләнә башлавына – бер ел. Хәзерге вакытта фермасында 50 башка якын терлеге бар. Биш ел эчендә аларның санын 100гә җиткермәкче була. Моңа кадәр мәктәп директоры, спорт комплексы җитәкчесе булып хезмәт куйган Рөстәм ни сәбәпле терлекчелеккә килергә булган соң? Бу хакта ул үзе менә нәрсә ди:

– Районыбызга яңа башлык куелгач, эш юнәлешемне тамырдан үзгәртергә карар кылдым. Ә ни өчен авыл хуҗалыгы дигәндә, беренчедән, соңгы елларда әлеге тармакка игътибар да, ярдәм дә зур. Икенчедән, пандемия авыл хуҗалыгының перспективалы тармак булуын күрсәтте. Сөтчелек юнәлешен сайлап та оттырмаганмындыр, дип уйлыйм.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Төп ставка кими

Үзәк банк төп ставканы 20дән 17 процентка калдырган. Банкта билгеләп үтелгәнчә, икътисад өчен тышкы шартлар катлаулы булып калса да, илнең финанс тотрыклылыгына янардай куркынычлар кими. «Депозитларга тотрыклы рәвештә акча керү күзәтелә. Соңгы атналарда, шул исәптән сумның ныгый башлавы нәтиҗәсендә, бәяләр үсү акрынайды. Алдагы утырышларда төп ставканы тагын да күбрәк киметүне күздә тотабыз», – диелә Үзәк банк хәбәрендә.

Төп ставка күләмен яңадан карау буенча чираттагы утырыш 29 апрельгә билгеләнгән.

Без –147 миллион

Бөтенроссия халык санын алуның башлангыч йомгаклары билгеле. Ахыргы мәгълүматлар май аенда игълан ителәчәк, дип яза ТАСС. Башлангыч мәгълүматларга караганда, илебездә 147 миллион кеше даими яши. Исегезгә төшерәбез: Росстат узган елның 1 гыйнварына Россиядә 146 миллионнан артыграк кеше исәптә, дип игълан иткән иде. Ведомство башлыгы Павел Малков әйтүенчә, ахыргы нәтиҗә чама белән 0,3 процентка үзгәртелергә – 400–500 кешегә артыграк яки кимрәк булып чыгарга мөмкин. Бөтенроссия халык санын алуның тулы йомгаклары быел декабрь аенда гына игълан ителәчәк. Анда илдә яшәүчеләр саны гына түгел, бәлки торак шартлары, телне белү һ.б. турында мәгълүматлар да күрсәтеләчәк.

Җанисәп 2021 елның 1 октябрендә башланып, 14 декабрьдә төгәлләнде.

Яз шаулап килә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанга Балтыйк диңгезеннән циклон үтеп керү сәбәпле кинәт җылыту карны бик тиз эретеп бетерергә һәм язгы ташуны тизләтергә мөмкин. КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев шулай дип белдергән. «Хәзер безгә җылы дулкын үтеп керде. Норма буенча тәүлеклек уртача температура +3 градус чамасы булырга тиеш, ә чынбарлыкта – күпкә югары. Төгәенләп әйтсәк, җылылык 5 градустан артып китте. Гадәттә табигать җанлана башлаган чорда гына шулай була», – дигән ул «Татар-информ» агентлыгына.

Белгеч билгеләп үткәнчә, быел уҗымнарга кар катламы астында озак утырырга туры килде. Апрель башында явым-төшем айлык норманы тутырды, дип әйтергә мөмкин. Менә хәзер кинәт җылытты. Ә бу язгы процессларны бик нык тизләтергә мөмкин. Аның әйтүенчә, һава температурасының якындагы 10 көндә нормадан 4 градуска җылырак булуы көтелә. Гәрчә әле ай башында гына тәүлеклек уртача температура нормадан кимрәк дәрәҗәдә теркәлсә дә. Переведенцев сүзләренә караганда, ял көннәрендә дә җылы һава саклана, явым-төшем көтелми. Шимбә көндез һава температурасы – 9, якшәмбе 11 градус җылы булачак. Ә дүшәмбе көнне көндезге сәгатьләрдә 14 градуска кадәр җылытачак.

Вазгыять

Онытырлык түгел

Коронавирус турында азрак сөйләвебез чирнең әле тулысынча юкка чыгуына бәйле түгел. Әле дә инфекция йоктырып, кешеләр хастаханәләргә эләгә тора, кызганыч, якты дөнья белән хушлашучылар да бар. Вирусның мутацияләве дә дәвам итә – галимнәр яңа төрләре турында сөйләп тора.

Ике елдан артык вакыт эчендә коронавирус белән бөтен дөньяда 496341342 кеше чирләгән. Үлүчеләр саны – 6170701.

Россия вице-премьеры Татьяна Голикова коронавирус белән авыручылар санының соңгы арада кимүе күзәтелгәнне белдерде. Аның әйтүенчә, бу инде планлы медицина ярдәмен күрсәтү эшен киңрәк алып баруны кире кайтару өчен яхшы этәргеч булып тора. Вице-премьер илдә диспансеризация һәм медицина тикшерүләрен оештыруны тәэмин итәргә кирәклеген ассызыклады.

Шулай да коронавирусның яңа дулкыны булу да ихтимал. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко ил халкын шул хакта онытмаска өндәде. Гамәлдәге профилактика һәм саклык чараларын үтәү әһәмияте кала. Моңа өстәп, вакцина һәм ревакцинация ясату турында да онытмаска.

Вакцинация димәктән. Вирусолог Петр Чумаков сүзләренчә, пандемиянең 2022 елда бетүен көтәргә кирәкми. Чөнки Җир шарында яшәүчеләрнең яртысы әле һаман да инфекциягә каршы прививка кадатмаган. Фаразларга карасаң, вазгыять кискенләшергә мөмкин.

Татарстанда исә соңгы тәүлектә COVID-19 чиреннән терелүчеләр саны авыручылар күрсәткеченнән ике тапкыр артып киткән. 258 сырхауның 90ын хастаханәгә салганнар иде. 538 кеше сәламәтләнеп чыккан.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вакцина ясатучыларга килгәндә, республикада андыйлар 2506650 кешегә җитте. Ревакцинация узучылар – 288845 кеше.

Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсендә битлек кию режимын күптән бетерделәр. Моннан тыш Кемерово, Калуга, Тамбов, Тверь өлкәләрендә, Красноярск краенда да битлек кимиләр. Европаның кайбер шәһәрләрендә дә аны таләп итмиләр. Татарстанда исә әле дә транспортта, җәмәгать урыннарында битлектән булу таләп ителә. «Битлек кию режимын үтәү – федераль норма, ул Россиянең баш дәүләт санитар табибы карарында беркетелгән. Шуңа күрә бу юнәлештә ниндидер үзгәреш була икән, шундук битлек режимы гамәлдән чыгарылачак. Безнең барлык норматив документлар нәкъ шушы федераль күрсәтмә нигезендә төзелгән», – дигән иде Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина журналистлар белән соңгы очрашуында.

Сүзгә-сүз

Чулпан ИЛДАРХАНОВА, Татарстан Фәннәр академиясенең гаилә һәм демография үзәге директоры:

Соңгы елларда кияүгә чыкмыйча гына бала алып кайтырга теләгән хатын-кызлар кимеде. Элек алар баланы үзләре генә тәрбияләргә әзер булса, хәзер гүзәл затларның фикер сөреше сизелерлек үзгәрде.

(«KazanFirst»ка әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ЮМАРТЛЫК

Казанда кирәкмәгән әйберләрне башкаларга бушлай бирү очраклары арткан. «Авито» порталы белгечләре әнә шундый нәтиҗәгә килгән. Әлеге хезмәттән файдаланучы Казан кешеләренең 2,1 проценты март аенда бушлай әйбер тәкъдим иткән. Бигрәк тә йорт һәм бакча кирәк-яраклары бик юмарт өләшенгән.

БУШЛАЙ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘЙБЕРЛӘР КҮРСӘТКЕЧЕ

1	Мәскәү	14%
2	Санкт-Петербург	5,6%
3	Краснодар	2,4%
4	Казан	2,1%

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя, 6 айга **423 сум 48 тиен** — гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя, 6 айга **942 сум 18 тиен** — гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Маймыллыктан чыгып җитмәгәч...

«Белем дәрәҗәсе түбән җәмгыять, гыйлемле җәмгыять белән чагыштырганда, һәрчак рәхимсезрәк. Анда изү, ирексезләү, тигезсезлек күбрәк, куерак. Әхлак азрак». Мондый билгеләмәне кайсыдыр артык акыллы кеше әйткән дип уйларга кирәкмидер. Башында уй булган һәркем иртәме-соңмы андый бәйләнеш барына төшенә. Гыйлем үзе исә, сәләттән дә бигрәк, беренче башлап тәрбиягә һәм дә әхлакка барып тоташа кебек. Чын гыйлем иясе вакытында яхшы тәрбия алган, тәрбия һәм белем әхлаклы иткән зат булыр. Гәрчә белемле вәхшиләр, явыз даһилар очраштыргаласа да. Әмма алда язганнардан барыбер шундый нәтиҗә чыгарып булыр иде: дөньяны бәхетле итәр өчен, аны бары гыйлемле һәм тәрбияле итәсе генә. Тәрбия һәм гыйлем булганда, әхлак яралмый кала алмый.

Бу юлларны мин Халыкара әхлак көненә (Международный день нравственности) бәйле рәвештә язам. Әйе, андый көн дә бар. Ләкин БМО билгеләгән мөһим һәм затлы даталар: Халыкара толерантлык көне, Халыкара тынычлык көне, Халыкара көч кулланмау көне (Международный день ненасилия), Халыкара үзара тыныч яшәү көне һ.б. гамәлдә торуга да карамастан, кызганыч ки, алар – мәҗбүри үтәлүгә, реаль көчкә ия булмаган декларатив көннәр. Әлегә алар теләкләр җыелмасы, бары шигарьләр генә булып кала. Ник шулай соң?

Кешелек цивилизациясенә әле нибары 5–6, күп булса 10 мең ел. Билгеле бер биологик төр, төркем, андагы коллектив акыл өчен бу – бик аз вакыт аралыгы. Кешелек әлегә – биләүдәге имчәк баласы гына. Аның нинди сыйфатта җитлегәсен фаразлау да авыр. Миллион еллар барган эволюция нәтиҗәсендә җанвардан кешегә әверелгән, цивилизация берәмлеге булган адәми зат – маймыллыктан чыккан, тик чын кеше булып җитешә алмаган биологик төр. Аның бүген билгеле бер күләмдә акылы, фикерләү сәләте, хәтере бар, ул нәтиҗәләр чыгара белә. Тик ул камиллектән нык ерак. Биологлар да кеше геномының хайваннарныкыннан нибары бер процентка (!) гына аерылуын әйтә. Кыргыйлык, инстинктлар, ил-көндәге әхлаксызлык менә кайдан.

Әйе, кыргый табигатьтә әхлак юк һәм була да алмый. Чөнки табигатьтә, мәгълүм ки, яшәү, исән калу өчен миллиард еллар буе рәхимсез көрәш бара. Ул һәрчак агрессиягә бәйле. Кыргый табигать эволюциясе әхлакны белми: эре хайваннар вакларны тотып ашый, ваклар исә һаман качу, котылу ысулларын камилләштерә, үз азык базасын киңәйтә. Бүре куянны ботарлый, кисәкләргә аера, бөркет, мәсәлән, елан белән туена. Елан, үз чиратында бака, тычканнарга рәхим-шәфкать күрсәтми. Кайда монда әхлак, шәфкать дигән категориягә урын? Бер яктан уйлаганда, кешеләр арасында әхлак дигән сүзнең яралуы, әйләнешкә керүе, ул турыда сүз куерту үзе генә дә зур казаныш кебек. Ихтимал, ул категория – илаһи зат Аллаһы үзе индерергә алынган, тик әлегә индереп бетермәгән сыйфаттыр.

Геннарында кыргыйлык яшәп тә, «homo sapiens» (человек разумный) исеме алган җан иясенең шәхси сыйфатлары әлегә шактый түбән. Әлбәттә, безнең арада гомере буе Аллаһының барлыгына, берлегенә ышанып яшәгән изге затлар, адәми затның холык-фигылен, асылын яхшы аңлаган мәшһүр язучылар, Нобель премиясе лауреатлары, академиклар, галимнәр бар. Тик төрле калыптагы җинаятьчеләр, мәңге кипмәс сәрхушләр, гомере буе бер изгелек тә кылмаган гөнаһ ияләре, башка төр адәм актыклары алардан күбрәк. Җирдәге белем системасы кешене, зурдан алганда, укырга һәм язарга гына өйрәтә. Урта белемле уртакул зат һич тә гыйлем иясе түгел. Югары белем дә аны гарантияләми. Белем бирү системасы күпчелек илләрдә җайга салынган булса да, кешене чын кеше итү алгоритмы планетада әле эшләнмәгән. Һәм бу хәл – кешелекнең бүгенге төп бәласе, хәтта ки фаҗигасе, сугышларсыз яши белмәү сәбәбе.

Бөртекләп гыйлем җыясы урында бөртекләп түгел, умырып мал, байлык җыю шаукымы да инде күптән тамыр җәйгән. Шушы хәл үзе генә дә әхлакка ирешүдә безне чабудан тартып тора. Бүген бит: «Ул кадәр акыллы булгач, син нишләп шулай ярлы соң?» – дип кенә җибәрәләр. Ягъни синдәге зиһен, акыл бер юнәлештә – күсе сыйфатында гына эшләргә тиеш булып чыга. Тик алны-артны карамый, ярыша-ярыша мал җыйганда, кешелеклелек, әдәп, намус, әхлак белән исәпләшү мөмкин микән ул?

Күпчелек дәүләтләрдә власть та халыкны гыйлемле, тәрбияле, аның белән бергә әхлаклы итү ягында түгел. Чөнки, беренчедән, алай идарә итү кыенлаша. Икенчедән, аңа киткәч, властьның үзенә дә әхлаклы, иманлы буласы. Алар аңа әзер түгел. Бу җәһәттән совет чорының икенче яртысы искә төшә. КПСС Үзәк комитеты, Политбюро үзен бик тә иманлы санады. Тик ул иман коммунистик иман иде. Шулай булып та, ул власть биредәге халыкта уку, укымышлылык культы тудыра алды кебек. Без ул чорда хакимиятне гомумән дә бүләк өләшүче Кыш бабай сыйфатындарак күрдек төсле: фатирга чаклы биргәч, ничек башкача уйлыйсың. Тик совет чоры дәүләтенең Левиафан вакытын – күпләрне чәйнәмичә йотуын да онытмасак иде...

Мораль һәм әхлак дигәндә XXI гасыр безнең өметләрне акламады. Кешелеккә ике Бөтендөнья сугышы китергән XX гасыр да акламады аны. Техник һәм технологик алгарыш тормышны яхшыртса да, кешелеккә моңарчы булмаган, күрелмәгән үтерү кораллары, яңадан-яңа корал системалары китерде. Ник шулай? Чөнки әлеге дә баягы рухи һәм әхлакый үсеш туктап калды. Мәгърифәт яңа үрләр яуламады, яңа әхлак институтлары тумады, диннәр йогынтысы көчәймәде, шәхес иреге артмады. Киресенчә, без яңа төр коллыкка кердек. XXI гасыр коллыгы ул – башкалардан кәттәрәк, баерак, уңышлырак булып күренергә теләү. Әйбер җыю, башыбызны томалап, акыл җыюны да оныттырды. Бишбылтыр балигъ булган малай-кызлар үзләре җыйган шул уенчыклардан аерыла алмый бүген. Әхлак сай: бәла килгәндә, ут чыкканда, аны сүндерергә ашыгучылар күп түгел. Ят янгында кулын җылытучы, аны тамаша кылучылар, битарафлар күбрәк.

Франсиско Гоя дигән рәссамның моннан ике гасыр элек үк ясалган, мәгълүм испан мәкален гәүдәләндергән «Зиһен йокысы албастылар тудыра» («Сон разума рождает чудовищ») дип аталган билгеле картинасы бар. Акыл һәм әхлак йокысы аркасында туган бүгенге көн албастылары алар – байлыкка табыну, имансызлык, мин-минлек, ялтырау. Затсызлыклардан котылып, чын кешелек сыйфатларын арттырасы иде безгә.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Казан Кремлендә ватерполчыларны котладылар. Башкаланың «Синтез» клубы быел Россия чемпионы булып танылды. Спортчыларга мактау һәм рәхмәт сүзләрен Президент Рөстәм Миңнеханов җиткерде.

tatarstan.ru

Казан клубы үз тарихында дүртенче мәртәбә чемпион исемен яулады. Шунысы да бар: якташларыбыз өченче ел рәттән илнең иң көчле командасы булып танылды. «Команданың үзебезнең ил спортчыларыннан тупланыу аеруча мөһим. Күбесе Россия җыелма командасында да чыгыш ясый әле», – диде Рөстәм Миңнеханов. Президент уенчыларга, тренерларга, клуб җитәкчелегенә һәм хезмәткәрләренә, Татарстан Су полосы федерациясенә, иганәчеләргә, җанатарларга һәм спортчыларның гаиләләренә рәхмәт әйтте.

– Татарстанда югары нәтиҗәләргә ирешү һәм спорт инфраструктурасын үстерү өчен бөтен көч куела. Бүген республикада 263 бассейн эшли. Шуларның 15е – 50 метрлы, алар дөнья һәм Россия стандартларына туры килә. Без бассейннар, боз шугалаклары, спорт комплекслары һәм мәйданчыкларына малайлар һәм кызлар мөмкин кадәр күбрәк йөри алсын дип тырышабыз. Медальгә юл йорт янындагы спорт объектыннан башлана, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Төймә чираттан коткара

Көтеп утырмыйм дисәң, кул астындагы мөмкинлектән файдаланырга кирәк. Татарстанның ЮХИДИ идарәсе белгечләре йомышы төшкән кешеләргә шушы кагыйдәне истән чыгармаска киңәш итә. Мөмкинлек дигәндә, «Дәүләт хезмәтләре» порталын (gosuslugi.ru) күздә тотулары.

Билгеле булганча, машина теркәү һәм йөртү таныклыгы алырга имтихан тапшыру кебек хезмәтләрдән файдалану өчен чиратка шушы портал аша да язылып була. Кешенең вакыты да янга кала, портал аша язылганда дәүләт пошлинасына да 30 процент ташлама ясала. Бу хакта журналистларга Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Евгений Прытков сөйләде. «Үзебезнең юнәлештә дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә чиратлар булдырмаска тырышабыз. Теге яки бу хезмәтне күрсәтүгә сорауны даими контрольдә тотабыз. Сорау артып киткән очракта, бу хезмәтне күрсәткән белгечләр санын арттырабыз», – ди ул.

Евгений Прытков сүзләренә караганда, узган ел Казан шәһәрендә бу юнәлештә барлыгы 450 меңнән артык дәүләт хезмәте күрсәтелгән. Шуларның 70 проценттан артыгы электрон рәвештә башкарылган. «Якын арада сорау – җавап рәвешендә эшләүче «Телеграм» каналыбызны да булдырырга җыенабыз. Анда кеше кызыксындырган сорауларына тиз арада җавап таба алачак», – дип сөйләде ул.

Билгеле булганча, дәүләт хезмәтләренең бер өлеше күпфункцияле үзәкләрдә дә күрсәтелә. «Күпфункцияле үзәк» дәүләт-бюджет оешмасы җитәкчесе урынбасары Руслан Нигъмәтуллин сүзләренә караганда, бүген әлеге оешмаларда күрсәтелгән 280 төрле хезмәтнең сигезе Эчке эшләр министрлыгы эшчәнлегенә кагыла.

Машина йөртү таныклыгын алмаштыру, чит ил паспорты ясатуга сорау аеруча зур, ди белгеч. Саннар теленә күчсәк, агымдагы ел башыннан гына да алты меңнән артык кеше күпфункцияле үзәк аша машина йөртү таныклыгы алган. «Безгә, гадәттә, теге яки бу сәбәп аркасында ЮХИДИ идарәсе бүлекчәсенә әлегә алмаган кешеләр мөрәҗәгать итә. Аерма бары шунда: әлеге бүлекчәдә таныклыкны көнендә үк кулга алып була. Безнең аша эшләгәндә ике атналап көтәргә туры киләчәк», – ди ул.

Узган ел Татарстанда чит ил паспорты ясатучылар ике тапкыр арткан. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан буенча идарәсенең миграция мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе Андрей Шулепов китергән саннардан аңлашылганча, узган ел республикада 60 меңнән артык кеше чит ил паспорты ясаткан. Чагыштыру өчен: 2020 елда бу сан 30 меңнән артмаган. «Яшерен-батырын түгел, моңа пандемия дә йогынты ясады. Чикләр ябык иде. Быел 2018–2019 елдагы күрсәткечләргә әйләнеп кайтырбыз дип өметләнәбез», – ди Шулепов. Чит ил паспорты ясатырга өлгермәгән кешеләргә исә ашыгырга киңәш итте ул. Ник дигәндә, тиздән җәйге яллар чоры башланачак. Тик быел чит илгә йөрүчеләр күп булыр микән?

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Учак ягу тыела

Татарстанда 25 апрельдән 15 майга кадәр янгынга каршы махсус режим кертелә. Шушы чорда республиканың 116 торак пунктында учак ягу, шашлык пешерү бөтенләй тыела. Шулай ук 75 бакчачылык ширкәтендә дә Май бәйрәмнәрендә шашлыкны табада кыздырып кына ашыйсы була.

Мисал өчен Балтач районын алыйк. Алан һәм Пыжмара авыллары халкына учак, чүп ягу тыела, алар утта ризык та пешерә алмаячаклар. Әлеге авыллар янгын куркынычы зур булган торак пунктлар исемлегенә кергән.

Татарстан Республикасының янгын күзәтчелеге буенча Баш дәүләт инспекторы урынбасары Максим Трущин аңлатканча, махсус режим кертелгәч, чүп, коры үлән яндыру һәм учак ягу бөтенләй тыела.

– Урманнарга һәм бакчаларга якын урнашкан урыннарда ут ягу тыела. Әмма әгәр сез яшәгән җир, янгын куркынычы тудыра торган торак пунктлар исемлегенә кермәгән икән, махсус таләпләрне үтәп, шашлык пешерергә була, – ди Максим Трущин.

Шашлыкны махсус урында һәм мангалда пешерергә кирәк. Өсте капланмаган учак өйдән яки бакча йортыннан – 50, ылыслы агачлардан 100 метр читтә, яфраклы агачлардан 30 метр ераклыкта булырга тиеш. Әгәр бакча мәйданында урын җитәрлек түгел икән, ул чакта учак каралты-курадан 5 метр ераклыкта ягылырга, коры үлән һәм чүп-чардан 2 метр ара калырга тиеш. Бу очракта учакның өсте капланырга тиеш. Әгәр мангалың юк икән, 0,3 метр тирәнлектә чокыр казырга кирәк. Коткаручылар шашлык пешерәсе урынны коры үләннән һәм агач ботакларыннан, чүп-чардан арындырып куюны сорый.

Максим Трущин сүзләренчә, коткаручылар халыкны кисәтеп йөри башлаган инде. Ә режим кертелгәч, алар рейдларга чыгачак. Ярамаган урында шашлык пешерүчеләр, учак ягучылар җавапка тартылачак. Шуңа да алар республика халкын алдан кисәтә. Урманнарны сакларга, учак якмаска кушалар. Шулай ук янгын куркынычы тудырган эшләрдән тыелып торырга, салют аттырмауны сорыйлар.

Мамадыш районы Иске Комазан авылы да урман янәшәсендә урнашкан. Анда яшәүчеләр ут белән уйнарга ярамаганны яхшы белә.

– Үзебез сакламасак, кем саклар? Бакча артында гына урман безнең. Электән үк чүп тә якмыйбыз. Шашлык та ашамыйча торып була, – ди шушы авылда яшәүче Гөлназ Шәрипова. – Безнең якларда төтен күренсә дә, хәзер килеп җитәләр. Шуңа күрә без инде тәртип бозмыйбыз.

Дөрестән дә, янгынга каршы махсус режим кертелгән вакытта штраф күләме икеләтә арта. Бу чорда аның күләме гражданнарга – 2 мең сумнан алып 4 мең сумга, вазыйфаи затларга – 15 мең сумнан 30 мең сумга, эшмәкәрләргә – 30 мең сумнан 40 мең сумга, юридик затларга – 200 мең сумнан 400 мең сумга кадәр. Әгәр учактан киткән ялкын аркасында урманга ут каба икән, гаепле кешегә карата җинаять эше ачыла. Моның өчен 200 меңнән алып 400 мең сумга кадәр штраф салырга мөмкиннәр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РӘХМӘТТӘН БАШКА СҮЗ ЮК...

Ярдәм янәшә

Кире кайта алмабыз инде. Казанга күченеп кайткан кешеләр әнә шулай ди. Россиягә Украина, Донецк, Луганск республикаларыннан эвакуацияләнергә мәҗбүр булган кешеләр саны 653 меңгә җиткән. Аларның 127 меңе – балалар. Бер меңгә якын кеше Татарстанга кайтты. «ВТ» журналисты туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган гаиләләр белән Казанның «Ливадия» шифаханәсендә очрашты.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Син – йөртүче, мин– кондуктор

Без килгән көнне «Ливадия»дә күченергә мәҗбүр булганнар өчен вакансияләр ярминкәсе оештырылган иде. Казанның 9 оешмасы халыкка эш тәкъдим итә. Күченеп кайтырга мәҗбүр булучылар 100дән артык һөнәр арасыннан үзенә эш сайлый ала. Аларны трамвай, автобус йөртергә, кондуктор булырга, заводларда эшләргә чакыралар.

Мариупольдән килгән 32 яшьлек Сергей Ханча белән без шунда таныштык. Ул да, хатыны Кристина да эш эзлиләр иде.

– Ярты ел элек Казанга күчәргә җыенган идек. Ул чакта танышларыбыз да чакырды. Тик хатынымның әнисе һәм әбисе китүебезне теләмәде. Шуларны тыңлап калдык. Безнең фатирны яндырдылар. Торыр җиребез калмады. Шуннан соң подвалда качып яшәргә мәҗбүр булдык. Әни белән әби анда калды әле. Алар әле дә, беркая да бармыйбыз, диләр. Ә без хатыным белән качтык. Бик озак бардык. Аннары безне Россия солдатлары күреп алды. Чик аша чыгарга ярдәм иттеләр, – дип сөйли Сергей.

Елмаерга тырышса да, күңелендә сагыш икәне әллә кайдан сизелеп тора. Мариупольдә калган якыннары өчен борчыла ул. Хәбәрләшә дә алмыйбыз, ди. Әмма өметләнә: алар ничек тә бер-берләрен табарлар. Сергей үзенә эш тә тапкан. Инженерлык өлкәсендәге эшен дәвам иттермәкче. Оешма җитәкчеләре, аны укытып, яңа һөнәрле итәргә, яхшы хезмәт хакы түләргә вәгъдә биргән. Ә менә Кристинага эш юк әле. Ул үзләрендә 15 елдан артык зәркән кибетендә эшләгән. Алар күңелләрен төшерми. Икесе дә эш табып, Казанда төпләнеп калырга җыеналар.

Светлана Ливак 17 яшьлек кызы белән килгән. Ул да үзенә эш эзли.

– Эшсез утырып булмый. Ничек тә алга таба яшәргә кирәк. Йортыбыздан берни калмады, – ди ул. Светлана трамвай кондукторы эшен сайлады.

Хәер, ул гына түгел, тагын ике ханым «Метроэлектротранс» оешмасы вәкилләре янында гариза тутыралар иде. Аларның берсе – трамвай йөртүче, икенчесе кондуктор булырга җыена.

Марина Аносова Волноваха шәһәрендә элек тә машина йөрткән. «Минем таныклыгым бар иде», – ди ул.

Аның ире, ату тавышлары ишетелә башлагач та, әйдә, илдән китик, дип үгетли. Тик Марина аны тыңламый. Гомер буе җыйган малын, йортын ташлап китәсе килми аның. Җитмәсә, маллары бар, эте, песие. Эшен югалтудан куркып, ул иренә каршы төшә. Әмма ире, ике баласын алып, Чехиягә китә.

– Хатын-кыз шул бит инде ул. Янәсе, йортны ташламыйм. Бер минут эчендә көлгә әйләнде ул. Иң элек этемне аттылар. Аны кызгануларым! Әле ярый, үзем качып калдым. Бернәрсәсез йөгердем дә йөгердем. Бер төркем кешеләр арасына килеп чыктым. Алар бомбалардан качар урын эзли иде. Мин аларга иярдем. Ничек итеп автобуска утырганымны, чик буена килеп җиткәнемне хәтерләмим. Көчле шок хәлендә булганмын, – ди ул. – Россия солдатларына рәхмәт. Алар безне каршы алып, озатып калдылар. Таганрогтан Казанга кайттык. Монда инде бөтенләй башка тормыш. Мин әле дә җир белән күк арасында яшим кебек.

Маринаның танышы Нина ханым да ире белән Казанга килгән. Алар инде пенсиядә. Әмма шуңа карамастан, ул да эш эзли.

– Актык көнне көтеп ятып булмый бит инде. Ашаталар, эчертәләр, җылы урын бирәләр. Бүлмәләрдә су бар. Ял итеп була. Әмма бу вакытлыча гына. Кешегә салынып ятып булмый. Үзеңә дә селкенергә кирәк, – ди Нина ханым.

14 апрельдә 69 яшен тутыра икән. Әмма әле кызлар шикелле. Марина трамвай йөртсә, ул кондуктор булырга җыена.

Казан «Метроэлектротранс» оешмасыннан эш тәкъдим итүчеләр күченеп килүчеләрнең хәленә керә. Алар үзләрендәге мөмкинлекләр турында сөйләп кенә калмый, аларны тынычландыра да, киләчәккә өмет тә бирәләр.

– Бездә тулай торак бар. Анда гаиләгез белән дә яшәп була. Хезмәт хаклары да начар түгел. Кондукторлар – кулларына 50 мең, трамвай йөртүчеләр 70 мең сум ала. Тулай торак бүлмәсе өчен 8 мең сум түләргә кирәк булачак. Иң мөһиме – сез кеше белән аралашып, күңелегезгә тынычлык табарсыз. Начар уйлардан арынып торырсыз, – ди алар.

«Ике көннән бетәр дигән идек»

Юлия Кузнецова «Казанская мельница» оешмасыннан эш тапкан. Ул Казанга өч баласы белән килгән. Иртәгә үк эшкә керер идем, ди.

– Без кичергәнне китап итеп язарлык. Шуңа да тизрәк кеше арасына чыгасым килә минем. Әле дә, күзне йомсам, күз алдында җимерелгән йортлар тора. Колакта танк, снаряд, бомба тавышы. Әгәр безне коткармасалар, акылдан шаша идек, – ди ул.

Юлия Мариупольдә яшәгән. Хәзер инде анда кайтмаячакмын, ди. Алар 25 көн караңгы подвалда утырган.

– Бездә элек тә шартлау тавышлары еш ишетелә иде. Шуңа да бер-ике көн булыр да бетәр дип уйладым. Бетмәде. Күңелгә шом керде. Тиз арада бер сумкага кирәкле документларны, азык-төлек запасы җыйдым. Күрше подъездга снаряд төшкән көнне без качу ягын карый башладык. Йортның подвалына төштек. Анда без йөз кешедән артык идек. Ул көнне йортыбызны җимереп бетерделәр. Бераз гына тынычлангач, чиратлап урамга чыга башладык. Мин әниемә подвалда икәнне әйтергә өлгердем. Ул безне 5 март көнне эзләп тапты. Күрше урамнан 1,5 сәгать ярым үрмәләп килгән, – дип искә ала Юлия. – Безнең йорттан ерак түгел икенче урамда әнинең апасы яши иде. Аның янына качып кына ике тапкыр бара алдык. Берсендә исән иде әле. Икенчесендә фатирына керә алмадык. Апаның кайдалыгын, исәнме-юкмы икәнен белмибез.

Юлиянең өч баласы: 22 һәм 15 яшьлек ике улы, 11 яшьлек кызы бар. Ике улына подвалда утырганда күрше әбисен җирләргә дә туры килә.

– Гаражлар артында буш урын бар иде. Без, әби үлгәч, күмәр урын эзләдек. Анда инде биш кабер барлыгын күрдек. Әби алтынчысы булды. Мин дә кабер казыштым. Без көн дә үлем белән очраша идек. Урамга чыкмыйча булмый, ә анда куркыныч, – ди 15 яшьлек Глеб. – Эчәргә суыбыз беткәч, 7 мартта яңгыр суы җыйдык. Безне Ходай кызганды, ахры. Ул көнне 6 сәгать яңгыр яуды. Шул су безне коткарды.

Глеб белән сеңлесен Казанның бер мәктәбенә урнаштырганнар. Әниләре исә, Татарстан халкына, елап, рәхмәтен җиткерә. Кем белән генә сөйләшмә, барысы да Юлия кебек рәхмәт укый. Аеруча Россия солдатлары турында җылы сүзләр әйтәләр.

Юлия Кузнецова Казанга килеп эләгүен мәңге онытмас.

– Санаторийга килеп кердек. Ут яна. Ятарга урын бар. Җылы су ага. Ашарга бирәләр. Тынычлык. Дөньяда иң зур бәхет шушы икән, дидем. Әнием, балаларым янымда, – ди ул.

Күченеп кайтырга мәҗбүр булучы кешеләр күргәннәрен тыныч кына сөйли алмый. Йөрәкләре тулы яра аларның. Әмма шулай да елмаерга көч табалар әле. Киләчәккә өметләре зурдан. Эш табачакларына, яңа тормыш башлаячакларына бик ышаналар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

КЫСТЫБЫЙ КЫЙССАСЫ

Мин килен булып төшкән елны ямьле җәй уртасында каенанамны хастаханәгә салдылар. «Йөрәге тыныч түгел», – дип аңлаттылар. Алты бала үстергән, аларның барысына да ана тәрбиясе биргән каенанамның үзе генә түгел, йөрәге дә талчыккандыр шул! Җитмәсә шушы ишле гаиләгә мин дә килеп кушылдым. Барлык йолаларына туры китереп, туй ясап, минем сөйгән ярымны да башлы-күзле иттеләр. Башлы-күзле булгандыр да булуын… Тик ир-атсыз гаиләдә, әби белән генә үскән яшь кызның киленлек хезмәте күрсәтү осталыгы әлегә бик тә чамалы иде…

Каенанам больницага кергәч, бу борчылу үзеннән-үзе чишелешен тапты табуын. Кыскасы, мин тормышымның яңа – килен хезмәте күрсәтү этабына күчтем. Шул көннән йортта яшәүче дүрт ир-ат – биатай һәм буй җиткән ике җанагай һәм дә үземнең ирем минем карамакка күчтеләр. Эшкә киткәндә, кирәк әйберләрен юнәтеп, озатып калу, эштән кайтканда аларны тәмле ашлар белән каршы алу минем көндәлек вазыйфама әверелде.

Ишле гаиләдәге хатын-кызның мәшәкатьләрен санап тормыйм, үзегезнең дә күргәнегез бардыр, тик шулай да килен хезмәтенең бер көнен сезгә дә сөйләп китәргә булдым.

Ул көнне мин эштән кайтасы ир-атларымны кыстыбый белән сыйларга уйладым. Иң беренче эш итеп учак астына ут төртеп җибәрдем. Кыстыбыйга дигән бәрәңгене казанга салгач, җиң сызганып, тышлыкка камыр әзерләргә тотындым. Өлгерәм икән әле, дип мичне дә ягып җибәрдем. Кыстыбый камыры әзер, пешерәсе генә калды.

Иң беренче булып төшке ашка биатай кайтып керде. Вакыт иртәнге тугызлар тирәсе иде. Зур гаиләдә бар да башкача, хәтта ашау вакытының да төрлечә булуын мин әле белми идем.

Биатай минем ниндидер ят ризык әзерләвемне күрепме, әллә инде миңа эшне җиңеләйтергә теләпме: «Бәрәңгесен генә бир дә, миңа шул җитә», – дип, өстәл янындагы урынына утырды. Мин дә үз чиратымда сүз куертып тормадым, ул ничек әйткән булса, шулай эшләдем. Тиз генә ашап алгач: «Мин йорт тирәсендә булам», – дип, биатай өйдән чыгып та китте. Озак та үтми тагын бер ир-ат кайтып керде. Анысы ике җанагайның көзгә армиягә китәргә тиешлесе иде. «Савымчыларны җәйләүгә илтәсем бар», – дип ашыкканлыгын сиздертеп, ул да өстәл янына килеп утырды. Холкы белән озак көтәргә яратмый торган егет икәнен мин бераз шәйләгән идем инде. Кыскасы, ул да тиз генә капкалап алгач, ихатадагы «Т-40» тракторын кабызып, күз ачып йомганчы чыгып та китте. Авыл буйлап савымчыларны җыярга кирәклеге турында белә идем.

Тик ул минутларда аның киләчәктә хәрби кеше булачагын, хәрбиләргә хас кырыслыгының хәтта аңа килешеп тә торачагын күзаллаудан мин әле ерак идем. Утыз ел хәрби хезмәттә булып, гомеренең соңгы көненә кадәр хәрбилеген югалтмаган туганыбыз, ә минем өчен ул – җанагай, барыбыз өчен дә өлге булып яшәде.

Йә ярый, әйдәгез! Кыстыбый пешерүне дәвам итик. Минем әле тагын ике ар-атны төшке аш белән сыйлыйсым бар.

Кыстыбыйга тышлык пешерә башлауга кече җанагай да кайтып керде. Мин инде аңардан, ашыйсың киләме, дип сорап тормадым, кыстыбыйга дигән бәрәңгенең соңгысын тәлинкәгә салып, алдына куйдым. Алдына килгән ризыкны калын итеп киселгән ике телем икмәк белән сыпыртып куюын әле дә елмаеп искә алам. Спорт белән шөгыльләнүче егетнең аппетиты, күз тимәсен, зарланырлык түгел иде.

Зур совхозның комсомолларын җитәкләүче ирем, ерак авылларга киткәндә, күп вакыт төшке ашка соңарып кайта торган иде. Ә бүген, рәхмәт төшкере, ул да уникe тулар-тулмаста кайтып керде. Без ул көнне төшке ашны икәүдән-икәү генә кыстыбыйга дигән җаемнәр белән чәй эчеп төгәлләдек. Яңа гына өйләнешкән көннәребез! Өстәлдә нинди ризык булуы бәлки безгә мөһим дә булмагандыр.

Кыстыбый кыйссасын шушы урында тәмам итеп, нокта куйсак та хата булмас иде кебек. Юк шул! Минем әле кичкырын каенанам янына барасым бар. Бәрәңге боламыгын өр-яңадан пешереп, каенанам янына мин инде чын кыстыбый күтәреп бардым. Хәл-әхвәлләрне сорашып, өйдәге хәлләр белән таныштыргач, кыстыбый турында да сөйләп ташладым.

Әллә инде минем хәлемә кереп, әллә үзенең өйдә була алмавына борчылып, ишле гаиләдәге аш-су әзерләүнең кайбер нечкәлекләрен гади итеп кенә миңа аңлатырга тырышты.

Каенанам биргән киңәшләрне язып тормаска булдым. Барысына да тормыш үзе өйрәтә! Кайчан кыстыбый пешерергә, ә кайчан ир-ат өчен ипи белән чәйнең дә иң тәмле ризык булуын мин дә яши-яши төшендем.

Һәр гаиләнең үз сере, үз нечкәлекләре булган кебек, бу истәлекле көн килен буларак минем өчен беренче дәрес тә, беренче имтихан да булды. Менә инде 55 ел мин бу гаиләгә, шул гаиләдә тәрбия алган туганнарыма, бигрәк тә биатай белән бианайга рәхмәтле булып, ирем вафат булгач та аларга булган хөрмәтемне сүрелдермичә, тормышымны дәвам итәм. Яхшы гаиләгә туры килү – кыз бала өчен үзе үк ярты бәхет, дияр идем.

Алсу ГАБДЕЛХАКОВА.
Азнакай

ЙӨРӘК ӘРНИ, КҮҢЕЛ ТЕЛГӘЛӘНӘ…

ЦИРК ТУРЫНДА НИЛӘР БЕЛӘБЕЗ?

Урта Азия, Кавказ халыкларында киң таралган атта чабышу, җайдакның чабып барганда төрле күнегүләр ясавы зур осталык, тәвәккәллек таләп итә.

Шундый тәвәккәл күнегүләрне җайдаклар «мәйдан» дип аталган тигез, чирәмле җирдә уздыралар. Аларның осталыгын күрү өчен түгәрәк мәйдан кирәк була. Минемчә «мәйдан түгәрәк» сүзен Европа халкы үзләренчә, латин сүзен кулланып, «цирк» дип йөртә башлыйлар, ягъни «circus» – түгәрәк була. Биек булмаган дивар-барьер белән чорнап алынган түгәрәк «арена». Аны цирк артистлары, горурланып, «манеж» дип йөртәләр. Цирк бинасы, тамаша залы, арена-манеж кагыйдәләренә буйсынып, түгәрәк итеп корыла. Залда утыручы тамашачылар, кайда гына утырсалар да, артистларның чыгышын төрле яктан күрә алалар.

Цирк манежы унөч метр киңлектә була. Тамашачылар өчен манеж тирәсенә түгәрәкләп амфитеатр төзелә, урындык-креслолар куела. Арена – манежның зурлыгын ат өйрәтүче, атта чабучы артистлар билгеләгән. Чөнки унөч метр диаметрлы аренада ат өстендә чабучы артистларга тигезлекне сакларга уңайлы. Ә ат өйрәтүче-дрессировщикларга арена уртасында торып, чыбыркы (шамбарьер) белән җитәкчелек итү җиңел була.

Аренаның өсте йомшак булырга тиеш, ул бигрәк тә артист-акробатлар өчен кирәк шарт. Узган гасырның сиксәненче елларына кадәр үзле кызыл балчыкны җәеп, йомшартып, пычкы чүбе белән бутап, барьердан манеж уртасына таба яссылык ясала торган була. Ул «писта» дип атала. Шундый яссылык булу мәҗбүри. Чөнки алар дәррәү чапканда, физика законы буенча уртага тарту тәэсире аркасында артистлар ат өстеннән егылып төшмиләр. Алар җиңел генә аттан сикереп төшеп, яңадан «үррә» чапкан атка атлана алалар.

Урта гасыр чорында атлы сугышчыга артык осталык кирәк булмаган. Ике яктан ике гаскәр башлыгы кара-каршы сугышып, озын сөңге белән дошманын аттан сугып төшергәч, ике гаскәр бер-берсенә ташланып, кылыч чабышы, үтерешләр башлаган. Яңадан-яңа сугышлар була торып, җайдак сугышчылар «төп йодрык» буларак сугышу, атта чабу, сугыш уеннарын үзләштерү мөһим бурычка әверелә. Җайдак сугышчы дошманыннан сакланып калу өчен бик оста хәрәкәтләр ясарга өйрәнергә тиеш була. Ат дәррәү чабып барганда җиңел генә аттан сикереп төшеп, дошманын уздырып җибәргәч, яңадан атына сикереп менеп атланып, көтмәгәндә һөҗүм итә…

Бу күнегүләрне европалылар «вальтижировка» дип атаганнар һәм шул термин бүген дә циркта кулланыла.

Монда инде үзебезнең татар студиясе турында да сүз әйтмичә һич мөмкин түгел. Советлар Союзында «Союзгосцирк»ның Үзәк цирк студиясе 1969 елда Татарстанда студиясен ачкач, кызлардан гына торган «Девушки-джигитки» дип аталган бик тә зәвыклы атлы төркем төзелде. Соңыннан, номерда катнашучы кызлар, туктаусыз трюклар иҗат итеп, музыканы, костюмнарны үзгәртеп, «Амазонкалар» дип аталып йөртелделәр.

Цирк программасын, гадәттә, һава гимнастлары башлый иде. Икенче татар циркы тарихының атлы номерлардан булуын искә алып, сүзне алардан башладык та. Татар циркы студиясенә конкурс уздырганда, атаклы Кавказ артистлары Кантемировлар гастрольдә, цирк программасында эшлиләр иде. Җитәкчеләре Ирек Кантемиров студиягә кабул итү әгъзасы буларак, конкурста актив катнашып, булачак «Девушки-джигитки» төркеменә абитуриент кызлардан кандидатлар сайларга ярдәм итеп, үзе булачак номерны әзерләде.

Шушы сүзләрдән соң, Казанда цирк тарихын 1890 елдан, бертуган Никитиннарның зур хезмәтеннән башласак, аларны хөрмәт итеп искә алу булыр иде.

Цирк сәнгате турында язарга омтылуымның сере бик гади: минем үземнең күпчелек эшчәнлегем цирк белән бәйле, цирк эстрада артистымын, заманында цирк фестивальләре лауреаты да булдым, Ярославль, Казан циркларында баш режиссер булып та эшләдем. Ни аяныч, хәзер Казаныбыз циркында миллилек тәмам онытылды, шулай итеп, тарих та юкка чыгып бара, шуңа йөрәк әрни, күңелем телгәләнә. Татар циркының үткәне турындагы вакыйгалар исә әледән-әле хәтердә яңара.

Альберт ГАДЕЛШИН

Соң булса да, уң булсын иде

Шулай беркөнне Александр Гордон белән Юлия Барановскаяның «Мужское – женское» тапшыруын карап утырам. 13 яшьлек яшүсмер суда бата башлаган ике балыкчыны коткара һәм МЧС хезмәткәрләре бу егетне «Суда батучыны коткарган өчен» медале белән бүләкләделәр. Ә мин, яшьләремә төелеп, моннан 26 ел элек булган хәлне күз алдына китердем.

Эссе җәй уртасы иде. Кызым Гүзәл белән улым Русланны Апас районы Болын-Балыкчы авылында кунакта калдырып киттем. Болын-Балыкчы авылы Зөягә бик якын урнашкан: балалар анда көн дә су коенырга йөриләр. Ул көнне дә иртәнге якта су керәләр, төштән соң да су коенырга баралар. Тик бер баруда 9–10 яшьлек Руслан елганың уртасынарак керә һәм бик көчле аккан су агымына эләгә. Агым аны бөтереп алып китә: бала бер батып, бер калкып йөзәргә тырыша. Кайсыдыр: «Руслан бата!» – дип кычкырган мизгелдә үзе белән бер елгы, ләкин гәүдәсе шактый калку Булат Кәлимуллин улым янына ташланган була инде. Тиз арада йөзеп килеп аны ярга алып чыга. Шулай итеп, Русланны суга батудан коткарып кала.

Шул игелекле балага күп рәхмәтләремне үзенә дә, гаиләсенә дә җиткердем, тик бүгенгә кадәр җаныма, күңелемә тынычлык таба алмыйм. Булат та бик зур батырлык эшләгән бит. Ул да – медальгә лаек егет. Соңга калып булса да, минем йөрәгемне тынычландырып, аңа «Суда батучыны коткарган өчен» медален тиешле органнар тапшыра алмас микән? Бу балаларга да тәрбия чарасы булыр иде, бүләкләү батырлыкның Башы кайдан икәнлеген белеп үсү өчен дә кирәк, дип исәплим. Булат – авылның гына түгел, районның да горурлыгы бит!

Улымны суга батудан коткарган Кәлимуллин Булат Нәҗип улы бүген Казан шәһәрендә яши, хезмәт итә, хатыны Чулпан белән малай һәм кыз үстерә. Бу игелекле ир-егетнең әтисе – Нәҗип абый «Татарстанның атказанган колхозчысы», әнисе Гөлсөяр – гомере буе авылда мәктәптә рус теле укытучысы булып эшләп, «Халык мәгарифе отличнигы» исеменә лаек булган мөхтәрәм зат. Булат гаиләсендә дә балаларның илнең лаеклы кешеләре булып үсәчәгенә иманым камил.

Лилия ГАЛИЕВА.
Казан

Кунак Тукай

Тукаебызның туган көне якынлашкан көннәрдә әтием сөйләгән истәлекләр хәтеремдә әледән-әле яңара. Әйтүенчә, авылыбызга – Башкортстандагы Аблай авылына кымыз белән дәвалану ниятеннән Габдулла Тукай килә, урта хәлле крестьян Әгъләм абыйлар гаиләсендә яши. Кымыз бияләре исә авылыбыздан биш чакрым ераклыктагы «Якты күл»дә була. Авыл старостасы безнең әтигә Габдулла Тукайны иртә-кич көн саен ат белән шунда алып барырга куша. Шулай итеп, алар ике атна чамасы аралаша, тарантаста җилдерәләр. Әти исән вакытта (ул 1982 елда дөнья куйды, авыр туфрагы җиңел булсын) Тукайны бик еш искә ала иде. Аның һәр сүзен, кыланышын, шигырь укуларын хәтерендә яңартты, без дә әтине бүлдермичә, сокланып һәм дә Тукай белән таныш булуына горурланып тыңлый идек. Тукайның ашыкмыйча гына сөйләшүен, башына түбәтәй киеп, кулын артка куеп йөрергә яратуын да ассызыклый иде.

Тукай авылыбыздан киткәндә, әтигә рәхмәт йөзеннән, китапларын да бүләк иткән. Тукайның безнең авылда булганлыгын, әтиебез белән таныш икәнлеген белгән студентлар, диплом эше язу максатыннан безгә килгәли дә иде. Хәзер инде үзем дә өлкән яшьтә, Тукайга бәйле хатирәләрне оныкларым бик рәхәтләнеп тыңлый, алар Тукаебызның шигырьләрен дә укый.

Флюра ӘХМӘДУЛЛИНА

МИНИСТРЛЫКНЫҢ «БОСС»Ы КЕБЕК ИДЕ

ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары булып 26 ел буе эшләгән Яков Павлухинның 1997 елда «История медицины Татарстана в лицах» дигән китабы басылып чыкты. Моңарчы мәкалә дә язып карамаган кешенең китап чыгаруы гаҗәп иде, әлбәттә. Ләкин Казан медицина мәктәбен даталар һәм фотосурәтләр белән искитмәле дәрәҗәдә матур һәм төгәл тасвирлап биргән саллы басма сәламәтлек саклау өлкәсенә азмы-күпме кагылышы булганнарның берсен дә битараф калдырмады.

Фотосурәтләргә гаять бай булуы (анда алар – меңгә якын) басманың кыйммәтен бермә-бер арттыра. Аны ачкач, шундук ахырына кадәр укып чыгу теләге туа. Гәрчә китап 408 биттән торса да.

Анда бик кыска гына, әмма аңлаешлы, кызык һәм мәгънәле итеп төрле язмышлар сурәтләнгән. Мәсәлән, Казан дәүләт медицина институтын тәмамлаган Сергей Курашов СССР сәламәтлек саклау министры булып эшләгән. Ә менә шул ук вузны тәмамлаган Ш.Хөсәенов 1953 елда табиб дипломы алгач, гомере буе сырхауханәдә участок табибы вазыйфасында хезмәт куйган. Өстәвенә әле соңгы 35 елда – шул бер үк урында.

Китап авторы Яков Павлухин – элекке хирург, медицина өлкәсендә танылган шәхес. Әйткәнемчә, 26 ел буе ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары булып эшләде ул. 60 яше тулуга, пенсиягә озатылды. Гәрчә ташып торган көч-энергиясе, гаять бай тәҗрибәсе сәламәтлек саклау өлкәсенә әле байтак файда китерергә мөмкин булса да. Хәер, чиктән тыш төгәллекне, пөхтәлекне яраткан, артыгы белән таләпчән җитәкче киткәч, аның кул астында эшләгән күпләр, шул исәптән мин дә җиңел сулап куйдык. Ләкин бик тиздән үк аның каты кулы җитмәгәнен сизә башладык. Казан Кремле үзәгендә урнашкан Сәламәтлек саклау министрлыгы бинасында янгыннан соң аеруча нык сизелде бу. Янгын, ремонт бетеп, түрәләрнең мебеле алыштырылганнан соң икенче көнне үк чыкты. Көпә-көндез! Министр бүлмәсендәге электрүткәргечтә кыска ялганыш барлыкка килү сәбәпле чыккан, диделәр. Шундый матди зыяннан соң таләпчән Павлухинны лаеклы ялга иртәрәк җибәрүләренә Министрлар Советы җитәкчеләре дә пошынып куйгандыр, мөгаен. Павлухин идарә иткән чагында мондый хәлнең гомумән дә булуы мөмкин түгел иде чөнки.

Көч-куәте ташып торган Яков Георгиевич лаеклы ялга чыккач та кул кушырып утырмады: китабына материаллар җыя башлады. Бер гасыр элек эшләгән табиблар турында мәгълүматлар җыю – чиктән тыш авыр эш. Аларны ул кая туры килсә – шуннан, хәтта архив чүплекләреннән эзләде. Коммунистик шимбә өмәсе вакытында Кремль дивары янында тапкан чираттагы «табылдыгы»на ничек итеп балаларча сөенгәне әлегәчә күз алдымда тора. Инде әллә кайчан гүр иясе булган табиблар турында бөртекләп мәгълүматлар җыеп йөргәндә, тапкан да инде шөгылен элекке «босс», дип мыек астыннан гына көлүчеләр дә булды.

Павлухин, чыннан да, Сәламәтлек саклау министрлыгында икенче түгел, ә нәкъ менә беренче кеше, «босс» кебек иде. 26 еллык эшчәнлеге дәверендә аңа берничә министр белән эшләргә туры килде. Тик аларның берсе дә сәламәтлек саклау өлкәсендәге төп мәсьәләләрне Яков Георгиевич белән килештермичә, аның хуплау сүзләрен ишетмичә генә хәл итмәде.

Локман ЗАКИРОВ



Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ТӘГӘРӘП КИТТЕ ТУБЫМ...

Спортның футбол дигән төре турында кемнәр күбрәк хәбәрдар икән?

1. Инглиз теленнән тәрҗемә иткәндә футбол сүзе нәрсәне аңлата?
А) туп һәм баскыч;
Б) туп һәм аяк табаны;
В) баш белән уйнау.

2. Футболдагы вакыт аралыгы ничек атала?
А) период;
Б) буллит;
В) тайм.

3. Бу һөҗүмче планетадагы иң яхшы футболчы дип танылды.
А) Пеле;
Б) Марадона;
В) Месси.

4. Футболның ватаны саналган ил.
А) Ирландия;
Б) Бразилия;
В) Англия.

5. Футбол матчының кагыйдәләре үтәлешен күзәтүче.
А) арбитр;
Б) психолог;
В) фониатр.

6. Лев Яшин ул – ...
А) Казанның «Рубин» командасы тренеры;
Б) совет футболчысы, капкачы;
В) танылган арбитр.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) А; 4) В; 5) А; 6) Б.

АСЛАН МИРГАЯЗОВ:
«ЯЛКАУЛАРНЫ ЯРАТМЫЙМ»

Үзе нәни генә, ә үзендә никадәр талант. Җырлый, музыка коралларында уйный, кинода да төшәргә өлгерә. Әлеге үткен, оста малай сәхнәдәге чыгышлары белән күпләрнең күңелен яулап өлгерде. Сүзебез – кечкенә йолдыз Аслан МИРГАЯЗОВ турында.

:: Аслан, ничә яшьтән бирле җырлыйсың инде?
– Мин 3 яшьтән җырлыйм. Җырлавымны күп кеше ярата иде, әлеге шөгыль үземә дә ошады һәм шулай җырлый башладым. Беренче тапкыр «Сәләтле бәләкәч» дигән конкурста «Әссәләмәгаләйкүм» җыры белән чыгыш ясадым.

:: Сәхнәдә син үзеңне чын артистларча тотасың, бер дә дулкынланмыйсың кебек. Моңа кем өйрәтте?
– Башта мин үзем җырчыларга карап өйрәндем, аннары вокал укытучым Чулпан Айдаровна Бикмиева булышты. Сәхнәдән курыкмыйм. Дулкынланмас өчен, гел шөгыльләнергә, ялкауланмаска, талантыңны үстерергә кирәк.

:: Татар җырчыларыннан кемнәрне тыңлыйсың?
– Иркәне, Ләйсән Гыймаева белән Булат Бәйрәмовны тыңлыйм, Илназ Сафиуллинның җырларын яратам. Илназ абый белән күптән түгел «Балалар премиясе»ндә чыгыш ясадык. Миңа бик ошады.

:: Җырлаудан тыш тагын ниләр белән шөгыльләнәсең?
– Хәзерге вакытта мин ике театр студиясенә йөрим. Берсе – Гөлнара Качалованың актерлык осталыгы студиясе, икенчесе – «Апуш» татар театр студиясе. Татар студиясендә бию, сәхнә теле, сәхнә хәрәкәте, вокал белән шөгыльләнәбез. Рус студиясендә сөйләм һәм хәрәкәт осталыгын үзләштерәбез. «Шаян ТВ»да «Шаяннар» һәм TMTV каналында «Балалы солянка» тапшыруларын алып барам.

:: Синең шөгыльләрең шактый икән. Кайсы күңеленә якынрак?
– Миңа вокал белән шөгыльләнү ошый, тик үскәч, актер булырга телим. Кинода төшкәнем дә бар. «Галиябану», «Микулай» һәм берничә кыска метражлы фильмда төштем. Ә узган ел «Билал» мөселман мультфильмын тавышландыруда катнаштым. Бәләкәй Билалны тавышландыру миңа бик ошады.

:: Буш вакытларыңда нәрсә белән шөгыльләнергә яратасың?
– Архитекторлар мәктәбенә йөрим, рәсем ясарга яратам. Фортепианода, курайда уйныйм.

Кунагыбыз турында белешмә

- Аслан – Флүзә һәм Алмаз Миргаязовлар гаиләсендәге төпчек бала.
- Яшь йолдызчыкка – 9 яшь.
- Ул Казанның 20 нче татар гимназиясендә 3 нче сыйныфта белем ала.
- Киләчәктә актер булырга тели.
- Җырлый, фортепианода һәм курайда уйный.

:: Иҗат юлында синең өчен кем үрнәк булып тора?
– Абыем Ислам. Ул да җырлый, курайда һәм фортепианода уйный.

:: Иң зур хыялың?
– Актер булу.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Ата-ана колагына

Әнием, син тыңла!

Ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре җиңел генә корылмый. Аңлашылмаучанлыклар да, баланың тыңламаган, кәефсез, көйсез мәле дә булмый калмый.

Танылган психолог Галия ГЫЙМАДИЕВАның кайбер киңәшләренә колак салсагыз, арадагы җепләрне ныгытуның җаен күрерсез.

1. ҖӘЗАСЫЗ КАЛДЫРЫРГАМЫ?
Гөлегез сулган икән, сез аны моның өчен шелтәләячәксезме? Юк. Сез ни өчен сулганын белергә теләрсез. Безнең балалар – безнең гөлләребез. Кемгәдер игътибар дигән «ашлама» җитми, кайсыларын көнчелек дигән «корт» кимерә, кемгәдер терәк-таяныч кирәк. Һәрвакыт башта сәбәбен эзләгез.

2. ДУС БУЛМАГЫЗ!
Балага «дустанә мөнәсәбәттә булу» һәм «дус булу» арасында аерма бар. Кем ул дус? Сезнең белән бер дәрәҗәдә, бер яссылыкта булган кеше. Сез шатлык-борчуларыгыз белән тигез дәрәҗәдә уртаклашасыз. Балалар белән шулай булырга мөмкинме? Әйе, мөмкин. Күп кенә ата-аналар балаларына зарлана, эшенә кагылышлы борчуларын сөйли. Сорау: балаларга бу кирәкме? Гаиләдәге табигый иерархия бозыла икән, бу үз нәтиҗәсен бирми калмый. Ягъни балалар көйсезләнергә, тыңламаска, кечкенә диктаторга әверелергә дә мөмкиннәр.

3. ӨЧ МИНУТ
Гаиләдә шундый гадәт кертергә мөмкин. Балагыз белән берникадәр вакытка аерылып торганнан соң, очрашу белән бер-берегезгә өч минут вакыт бүлеп бирегез. Башыгыздагы барлык мәшәкатьләрне онытып, эш турында уйламыйча торыгыз. Игътибарыгыз балага юнәлсен. Нибары өч минут. Аның уңышларына сөенегез, фикерләшегез. Нибары өч минут. Ә шул вакыт эчендә бала сезгә бөтен дөньясын ачып салыр.

Уйнап алабыз

ЭНӘ, ҖЕП, ТӨЕН

Бу уен ачык һавада да, бүлмәдә дә уйнала.
Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала – энә, икенчесе – җеп, өченчесе төен булып, шул тәртиптә бер сафка тезеләләр. Энә, балалар арасыннан төрлечә йөреп, җеп белән төенне адаштырырга тырыша. Тегеләре бер-берсеннән калмыйча аның артыннан йөриләр. Әгәр берәрсе адашып калса, аның урынына икенче бала уйный. Ә тегесе түгәрәккә баса. Уен шулай дәвам итә.

МИЯУ-МИЯУ, НИНДИ ТӨС?

Балалар санамыш ярдәмендә бер «песи» сайлап куялар.
Калганнары бер сафка тезелә. Песи алга баса һәм: «Мияу-мияу!» – ди. Балалар: «Нинди төс?» – дип сорыйлар. Песи бер төсне атый. Мәсәлән, сары булсын, ди. Балалар тизрәк якын-тирәдәге сары төстәге әйберне тотарга тырышалар (сары күлмәк, салам һ.б.). Андый әйбер тапмаган бала тиз генә йөгереп китә. Песи аны тотарга тиеш. Тота алса, тотылучы песи булып, тота алмаса, үз урынында калып, уен шулай дәвам итә.

Шаян хикәя

Куян күчтәнәче

Ильяс белән Закир шәһәрдә яшиләр. Ә ял көннәрендә, каникулда авылга кунакка кайталар. Аларны анда әбиләре, бабалары зарыгып көтә. Тагын күп җан ияләре көтә малайларны: Алисә исемле кәҗә, Роза исемле песи һәм аның Шаян атлы бәбие, Зебра исемле үгез малае, куяннар... Куяннар читлектә яшиләр. Ильяс белән Закир аларны бигрәк ярата. Җәй көне кәбестә, кишер, әрекмән белән сыйладылар. Су эчерделәр, сыйпап яраттылар.

Көз җитте. Мәктәптә укулар башланды. Авылга ялларда гына кайтыш хәзер. Малайлар соңгы кайтуда аптырап калдылар – куяннар юк! Бабалары әйтә: «Качканнар, урманга сыпыртканнар инде...» – ди. Әбиләре читлекнең ишеген ябарга оныткан шул. Ә куяннар җитез бит алар. Шалт – чыкканнар да чапканнар менә. Куяннарны бик сагынсалар да, малайлар еламады. Роза һәм Шаян белән уйнап, Алисәне, Зебраны сыйлап юандылар. Тора-бара хәтта куяннар турында оныттылар да бугай.

Менә җәй җитте – каникул! Ильяс белән Закир шатланып авылга кайттылар. Ууу, монда җәй көне эш күп! Әбиләре бакчада мәш килә, бабалары малларга ризык әзерли, печәнгә йөри. Малайлар да уйнап кына вакыт үткәрмиләр, өлкәннәргә булышалар.

Беркөнне бабалары печәннән кайтты да оныкларны янына чакырып алды. Кулында төенчеге дә бар. «Ягез әле, улларым, куян чәе белән сыйлыйм әле сезне. Куян күчтәнәче тәмле була ул», – дип, малайларга чәй салып бирде, күмәчләр өләште. Ильяс белән Закир иреннәрен ялый-ялый ашадылар. Куян күчтәнәче бик тәмле иде. «Абый, белдем!» – дип кычкырып җибәрде кинәт Закир. «Бу күчтәнәчне безнең куяннар биреп җибәргән бит инде! Безне онытмаганнар алар!» Әйбәт куяннар икән. Юмарт куяннар икән.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 250

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+